СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 8-1 от «22» сентября 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2019 елның 29 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында» № 5-32 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2024 елның 18 октябрендәге 1-31/15348 номерлы хаты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2019 елның 29 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында» № 5-32 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәгә түбәндәгеләрне өстәргә:

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1.8 пункт өстәргә:

«4.1.8. Үз функцияләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын файдаланырга.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы В.И.Никитин

000095